*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

# ТЫЛСЫМ+

Җиденче сан

Март, 2015 нче ел

## Бу санда:

*Гимназия сулышы* 1

*Талантлар ачыла* 2

*Укучыларның проект эше* 3

*Иҗади сәхифә* 4

## Гимназия бүген



**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – Татарстан Республикасының электрон белем бирү компетенция үзәге.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – Россия “Милли мәгариф” проекты җиңүчесе – 2008.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – “Укучыларның туклануын оештыру буенча иң яхшы мәктәп ашханәсе” VI Республика конкурсы җиңүчесе - 2009.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – медицина кабинетларының Республика смотр-конкурсы җиңүчесе - 2014.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – “Сәламәтлек саклау юнәлешендә “Алтын дәрәҗә”ле мәктәп” квалификацион характеристикасына ия булган уку йорты - 2014.

**Б**ЕЗНЕҢ ГИМНАЗИЯ УЛ – 405 укучы, 46 укытучы бердәм эшләүче коллектив.

## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

*Чын укытучы укучысына меҢ еллар хезмәт көче куелган әзер бинаны күрсәтми, ә төзелеш материалын эшкәртүгә юнәлеш бирә, аның белән бергә бинаны төзи һәм төзергә өйрәтә.*

*Адольф Дистервег*

### Каюм Насыйри исемендәге XIII яшүсмерләр фәнни-тикшеренү укуларының төбәкара конференциясе




Инновацион технологияләрдән уңышлы файдалану, фәнгә иҗади якын килеп эшләү зур нәтиҗәләргә ирешергә ярдәм итә. Укучылар белән фәнни-тикшеренү эшләре башкару, проектлар яклау – бүгенге көн таләбе. Укучыларның танып белү мөмкинлекләрен, акыл эшчәнлеген, мөстәкыйльлеген үстерүдә мондый юнәлештәге эшнең кыйммәте зур. Казан шәһәрендә 23 мартта Каюм Насыйри исемендәге XIII яшүсмерләр фәнни-тикшеренү укуларының төбәкара конференциясе узды. Гимназиядән бу укуларда 5 укучы катнашты. 9 нчы Б сыйныфы укучылары Бәдертдинова Динара туган якны өйрәнү юнәлешендәге, Ханеева Камиля география секцияләре эшендә катнашып, Грамота белән бүләкләнделәр. 11 нче В сыйныфы укучысы Габдуллина Зарина татар әдәбияты (проза) секциясендә җиңүче Грамотасына ия булды. 9 нчы Б сыйныфы укучысы Харисова Лиана “Халык авыз иҗаты” юнәлешендәге фәнни-тикшеренү эшен яклап, III дәрәҗә Дипломга лаек булды, Аглиуллина Язилә геоэкология секциясендә III дәрәҗә Диплом иясе булды. Укучыларның фәнни җитәкчеләре Э.В.Тимергалиева, Л.Ф.Бариева, Г.Н.Рахимуллина.



### “Илһам” бөтенроссия яшь язучылар бәйгесе

18 март көнне Әлмәт шәһәренең Риза Фәхретдин исемендәге татар гимназиясендә “Илһам” бөтенроссия яшь язучылар бәйгесенең икенче этабы узды. Сайлау турыннан узган 8 нче а сыйныфы укучысы Илүзә Кашапова һәм 10 нчы а сыйныфы укучысы Нәзилә Сәрварова уңышлы чыгыш ясадылар. Мәртәбәле жюри укучыларның эшен югары бәяләде, алар Г.Тукай туган көненә багышланган форум кысаларында оештырылган республикакүләм чарада катнашачаклар.

### II Россиякүләм ФОАТ САДРИЕВ УКУЛАРЫ - 2015

Ике ел рәттән безнең районда татар халык язучысы, Габдулла Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе Фоат Садриев укулары оештырыла. Укучылар фәнни җитәкчеләре – татар теле мөгаллимнәре белән берлектә төрле дәрәҗәдә эзләнү-тикшеренү эшләре башкаралар. 27 нче мартта безнең гимназиядә Татарстан Республикасы Язучылар Союзыннан, “ТАТМЕДИА” ачык акционерлык җәмгыяте филиалы “Мәгариф” журналы редакциясеннән кунаклар көтелә. Казан шәһәре, Яр Чаллы, Минзәлә, Түбән Кама шәһәре, Мөслим, Тукай, Әлмәт, Бөгелмә, Тукай, Азнакай, Сарман, Актаныш, Мамадыш, Чирмешән, Зәй, Арча муниципаль районнары гомуми белем бирү мәктәпләре, гимназияләреннән 8-11 нче сыйныф укучылары, укытучылар катнашачак. Әлбәттә, бу чараның иң мәртәбәле кунагы – Фоат ага Садриев үзе! Конференция эшендә уңышлар телибез!

## ТАЛАНТЛАР АЧЫЛА

### Шагыйрә Клара Булатова исемендәге премия тапшыру тантанасы



20 нче мартта Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институтының актлар залында әдәбият өлкәсендәге казанышлары өчен шагыйрә Клара Булатова исемендәге премия тапшыру тантанасы уздырылды. Тантанада шагыйрә Клара Булатова үзе, Әлмәт Язучылар оешмасы вәкилләре, Әлмәт, Азнакай шәһәрләре идарәсеннән вәкилләр катнашты. Әлеге чара Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты инициативасы белән үткәрелә.

Конкурс гомуми урта белем бирү мәктәпләре, лицей, гимназия укучылары, югары уку йортлары студентлар арасында уздырылды. Катнашучылар "Әдәби иҗат" һәм "Фәнни эш" юнәлешләре буенча көч сынашты. Конкурс әдәби-иҗат процессын стимуллаштыру, яшь буынның рухи һәм әхлакый үсешенә йогынты ясау, шулай ук Клара Булатова иҗатын пропагандалау максатыннан оештырылган. Без шушы тантанада катнашу бәхетенә ирештек. Клара Булатованың Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләгенә тәкъдим ителүчеләр исемлегенә кертелүе турында хәбәр тананада катнашучыларның хуплаулы алкышларына күмелде.

Тантана Клара Булатованың Туган як гимнына әверелгән "Шушы яктан, шушы туфрактан без" дип аталган җыры белән башланып китте. Шагыйрә үзе чыгыш ясады, аның шигырьләре яңгырады, иҗатына багышланган фәнни эшләр, яшь каләм тибрәтүчеләрнең иҗади эшләре тыңланды, драма әсәрләре сәхнәләштерелде.

Безнең гимназиядә оештырылган "Былбыл" иҗат берләшмәсе быел конкурска укучыларның хикәяләр һәм шигырьләр җыентыкларын тәкъдим итте. Гимназия I дәрәҗә Диплом һәм 3000 сум күләмендә премия белән бүләкләнде. "Былбыл" иҗат берләшмәсе җитәкчесе Тимергалиева Э.В. безне иҗатка тарту, иҗат җимешләрен пропагандалауның төрле юлларын таба. Гимназия укучылары иҗатын туплап, өч җыентыгыбыз дөнья күрде. "Серле каләм", "Язам әле" шигырьләр тупланмасы һәм "Фатихалы гомер" хикәяләр җыентыгы гимназия директоры А.Ф.Мирзаянов инициативасы белән нәшер ителде.

Шәхси нәтиҗәләр дә куанырлык: 8а сыйныфы укучысы Илүзә Кашапова "Әдәби иҗат" номинациясендә III дәрәҗә Диплом һәм премиягә ия булды. 9 нчы б сыйныфы укучысы Язилә Әһлиуллина, 11 нче а сыйныфы укучысы Ренат Мотавалов, 10 нчы а сыйныфы укучысы Нәзилә Сәрвәрова Дипломнарга лаек булдылар.

Гимназия укучыларының иҗатка тартылуы - матур күренеш. Алдагы елларда да яңа уңышлар сезгә, яңа үрләр яулавыгызны телибез.

***Әһлиуллина Язилә, 9 нчы б сыйныфы укучысы***

## АЛДА ЮЛЛАР, КАЙСЫН САЙЛАРГА...

**Ләйсән Ханова, 11 нче в сыйныфы укучысы:** Их, бу вакыт дигән нәрсә! Сизелмичә үтә дә үтә... Әле яңа гына зур-зур чәчәк бәйләмнәре тотып, беренче сыйныфка укырга кергән идек... Бөтен нәрсә беренче тапкыр: парта артына утырып, беренче укытучыбыз белән танышу да, ручка тотып хәрефләр язарга маташу да, тырыша-тырыша иҗекләрне кушып сүзләр уку да... Инде 11ел үтеп киткән. Бүген без үзебезне фән нигезләрен яхшылап үзләштергән, тормышка яраклашкан, креатив һәм конкурентлыкка сәләтле шәхесләр итеп тоябыз.

Әгәр тылсым көченә ия булсам, мин вакытны бер генә айга булса да туктатып торыр идем. Ни өчен дип уйлыйсыздыр инде. Вакыт үткән саен, сыйныфташларыбыз белән аерылышу көннәре якынлаша бит. Ә аерылышасы бер дә килми. Уку дәверендә без бер-беребезгә ияләшеп беттек, бер гаилә әгъзалары кебек якынайдык. Гимназиядә үткән елларны тормышыбызның иң якты хәтирәләре итеп күңелдә саклarбыз. Безгә белем, тәрбия биргән укытучыларыбызны сагынырбыз, сыйныфташларыбыз белән үткәргән кичәләр, төрле кызыклы чараларны сагынып искә алырбыз.


Алда – юллар... Алар безне киләчәккә илтә. Кайсы юлдан атласак та, барыбызга да уңышлар юлдаш булсын, гимназия биргән белем, акыл, тәрбиябез киләчәк бәхетебезгә нигез булсын иде!

**Илназ Гәрәев, 11 нче в сыйныфы укучысы:** Гомер дигән машинаның тизлеген киметеп булмый шул, Ләйсән. Әйе, 11 нче сыйныф укучылары өчен кызу эш өсте башланды. Әле имтиханнарга кадәр бераз вакыт бар, шулай да күп кенә иптәшләребез югары уку йортларында оештырылган "Ачык ишекләр" көннәрендә катнашып, укырга керү шартлары, таләпләр белән танышып кайттылар. Каникулларда төрле фәннәрдән ЕГЭ биреп, үз белемнәребезне, мөмкинлекләребезне сынап карадык.

Һәркемнең тормышта үз юлы була. Бәлки, барысы да укырга да кермәс. Ни генә булмасын, һәрберебезгә уңышлар юлдаш булсын! Киләчәгегез якты, хыялларыгыз изге булсын, дусларым!

***Чыгарылыш сыйныфы укучылары белән әңгәмәне гимназия президенты Алинә Сәхипгәрәева әзерләде***

## ТАЛАНТЛЫ ЯКТАШЛАРЫМА КҮҢЕЛЕМДӘ һӘЙКӘЛ КУЯМ



Шагыйрь **Харрас Гыйльмегали улы Әюпов** Түреш авылында туган.

Харрас Әюповка һәйкәл, һичшиксез, аның туган ягында булырга тиеш. Беренчедән, Харрас Әюп иҗатының буеннан-буена туган нигезе, Түреш авылы, аның искиткеч матур табигате, җырлы чишмәләре, кешеләре, атлары, кошлары белән аралашып-киңәшләшеп яшәде.

Икенчедән, әдипнең үзләре арасында сын рәвешендә генә булса да яшәвенә авылдашлары да бишкуллап риза булырлар иде, чөнки алар үз шагыйрьләре турында яратып, горурланып сөйлиләр. Харрас Әюп тә үз авылында булуны хуп күрер иде, чөнки ул Мөслимнең һәр почмагын сагына иде, аны үзенә илһам бирүче илаһи урын итеп карды.

...Сизелер-сизелмәс кенә таң сызыла. Күктә соңгы йолдызлар сүнә.. Кояшның алтын нурлары Түреш урманнарын әкрен генә кызгылт-сары төскә мана, чишмә суларын иркәли, Калмыя елгасына ашкынучы Түр инеш буйлап авыл эченә үрли... Авылның беренче әтәчләре уяна, кайдадыр ат пошкырып куя, ул арада ак яулык чөйгән яшь килен, кое сиртмәсен шыгырдатып, су алып кереп китә. Шул сихри күренешкә сокланырга, ап-ак мәрмәр һәйкәл булып, Харрас кайткан... Әйе, ап-ак костюмын җилкәсенә салган, ап-ак бөдрә чәчле, ак күңелле Харрас. Уйчан, таләпчән карашлары алга төбәлгән, башы горур күтәрелгән, иреннәрендә җиңелчә елмаю. Туган ягын, якыннарын сагынып, яратып карап тора, шул ук вакытта аның күңелендәге чиксез горурлык хисләре чагыла.

***Мөслим төбәге - күренекле шәхесләргә, талантларга бик бай төбәк. Алар иҗаты белән таныш булу – зыялылык билгесе. Яраткан язучыларга “Хыялдагы һәйкәл” проектын тәкъдим итәбез. Теманы өйрәнү барышында без үз асылыбызга кайткандай булдык, киләчәгебез турында матур уйлар туды, күңелләрне шулкадәр талантлар биргән Мөслим төбәге өчен горурлык хисләре биләп алды. Әлеге байлыкны башкаларга да җиткерүне үзебезнең бурычыбыз дип саныйбыз.***

***Проектта 8а, 9б сыйныфы укучылары катнашты.***

***Түбәндәге сораулар тәкъдим ителде:***

***Сез кайсы әдипкә һәйкәл куярга уйлыйсыз?***

***һәйкәл кайда булырга тиеш?***

***һәйкәл өчен нинди материал кулай булыр иде?***

***Әдипне нинди кыяфәттә итеп кузаллыйсыз?***

***һәйкәлгә нинди сүзләр язылган булырга тиеш?***

һәйкәл авылга кергән юл буеннан күренеп тора. Туган ягын, милләтен зурлаучы бөек әдипне һәркем танырга, зурларга тиеш. һәйкәл янында беркайчан да кеше өзелми, барлык бәйрәмнәр Харрас белән бергә үткәрелә. Бу авылда 80-90 яшьлек бабайлар, бернинди махсус белеме булмаган авыл картлары, Кандалый, Акмулла шигырьләрен, Тукайны яттан сөйлиләр. Аларны Харрас Әюп шигырьләрен сөйләүче яшьләр алмаштыра. Минем күңелемә дә шигырь килә...

***Тимур Салахов***



Шагыйрь һәм әдәбият тәнкыйтьчесе **Наис Гамбәр (Наис Гыймран улы Гамбәров)** Бүләк авылында туган.

Наис Гамбәр — татар әдәбиятын, халыкның рухи мирасын, телен һәм иҗтимагый фикер тарихын нечкәләп үзләштергән, шул нигездә әдәби процессны бөтен катлаулыгында күзәтеп-өйрәнеп баручы сәләтле тәнкыйтьчеләрнең берсе.

Ул — гавами шагыйрь булудан битәр, кеше күңелендә рухи җәүһәрләр эзләүче «камерный шагыйрь».

Наис Гамбәр һәйкәленең нинди материалдан булуы да, аның кайда урнаштырылуы да әһәмиятле түгел, минемчә, чөнки ул – үзе иң затлы хәзинә. һәйкәл Казанның һәм Мөслимнең дә затлы урыннарына урнаштырылып, һәр мизгелдә туган тел, халык, яшәү мәгънәсе, киләчәк, вөҗдан һәм башка мәңгелек кыйммәтләр турында искә төшереп, безне кәрәшкә рухландырып торсын иде. Аның янынан кыр чәчәкләре өзелмәсен һәм, тукталып, әдипнең шигырьләрен сөйләсеннәр, әлеге изге җирдән яшәү өчен көч, дәрт алып китсеннәр иде. Ә мин халыкка Наис Гамбәрнең “Теләү” шигырен сөйләр идем.

***Камилә Ханеева***

*Бәхеткә, безнең әдәбият – чын талантлар әдәбияты... Факил Сафин кебек прозаиклар белән телләсә кайсы әдәбият горурлана алыр иде.*

*Минтимер Шәймиев.*

*Факилнең һәр шигыре уйга сала, һәр шигыре яндыра. Берсеннән аерылып, икенчесенә кучеп булмый. Көчле шигырьнең тылсымы да нәкъ шунда шул – кешеләргә үз күңелләрен, йөрәкләрен аңларга ярдәм итә ул.*

*Зөлфәт.*

*Факилнең хикәяләрендәге вакыйгалар тормышның үзеннән сөзеп алынганнар. Бер карагaнда алар сатирик та, юмористик та шикелле, шул ук вакытта алар эстрада өчен дә түгел кебек, лирик юморга ия. Чеховча гап-гади буяулар белән тиеп-тиеп кенә алынган.*

*Мөдәррис Әгъләмов.*

Әлеге өч фикер язучы **Факил Сафин**ны бөтен яклап бәяли кебек. Факил кечкенәдән әдәбият, сәнгать белән кызыксынып үсә. Беренче әсәрләре белән үк укучыларның игътибарын яулап ала, тиз арада әсәрләрендә фәлсәфи бөтенлеккә ирешә алган үзенчәлекле язучыларның берсе булып танылa. Факил Сафин — «Соңгы көз» (1989), «Гөлҗиһан» (1994) повестьлары, «Биек тауның башларында» (1999) романы, «Саташып аткан таң» (2002) роман-трилогиясе, күп санлы хикәяләр, Кадыйр Сибгатуллин, Рәшит Бәшәр, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов һ.б. әдипләрнең иҗатлары буенча фәнни эзләнүле, тәнкыйди мәкаләләр; публицистик язмалар, шигырьләр, эпиграмма, пародияләр авторы.



Факил Сафин, минемчә, үзенә һәйкәлне үзе куйган шәхес. Туган авылы Әмәкәй халкы аның җырын үз Гимнына әверелдерде. Бу – үзенә күрә бер һәйкәл!

***Эльвина Солтанова***

## ИҖАДИ СӘХИФӘ

### СЕРЛЕ КЫЗ ИЛҮЗӘ




*Илүзә – бик сәләтле укучы. Дәрестә бирелгән эшләрне иҗади якын килеп башкарырга ярата. Аның сочинениеләре үзенчәлекле, тирән фикерле. Башкалар игътибар итмәгән гади генә нәрсәләрне дә ул серле итеп тасвирлап яза белә. Үзе шигырьләр иҗат итә. Җирле радио Илүзәнең иҗатына багышланган тапшыру эшләде. Илүзә Кашапова сценарийлар төзи, сыйныфтан тыш чараларны үзе алып бара. 2013 нче елда Актанышта Роберт Миңнуллин катнашында уздырылган республикакүләм фәнни-тикшеренү эшләре конференциясендә якташ язучылар иҗаты буенча чыгыш ясап, 1 дәрәҗә Дипломга ия булды. 2014 нче елда Илүзә Кашапова I Бөтенроссия "Ак җилкән" әдәби әсәрләр конкурсы җиңүчесе булды. "Казан утлары" журналында (№8, 2014 нче ел) "Фатихалы гомер" исемле хикәясе басылды. 2014 нче елда "Ильһам" бәйгесендә катнашып, "Проза" номинациясендә 3 нче урын алды, премия белән бүләкләнде. Бу уку елында Илүзә клара Булатова исемендәге премиягә лаек булды, "Ильһам" бәйгесенең икенче турында җиңү яулады. Гимназия укучыларының "Тылсым+" газетасы журналисты буларак, кызыклы репортажлар ясый, хикәя һәм шигырьләрен тәкъдим итә. Алар бик эчтәлекле, үзенчәлекле. Илүзәнең сөйләме бай, фантазиясе көчле. Сәләтле укучы гимназия тормышында да бик актив катнаша.*

*Хөрмәтле укучым! Иҗатка сәләтеңнең дәвамлы, бәрәкәтле булуын, тормышыңның күңелле вакыйгаларга бай булуын телим. Күңелеңдәге якты уйларың, матур хыялларың чынга ашсын! Ильһамлы иҗат мизгелләре аша сафланып, дәртләнеп яшәргә язсын!*

***Укытучың Тимергалиева Эльмира Василовна***

### ТАҢСЫЛУ (хикәя)

Илгә, көнгә иминлек теләп, Имәнәй тавы артыннан алсу нурларын чәчеп, әкрен генә кояш күтәрелеп килә. Кояшның тәүге нурлары, кызыл бүрегеН кырын салып, кетәклектә йокымсырап утырган чуар әтәчкә төште. Әтәч, кукрәген тутырып сулыш алды, иртәнге һаваны ярып, быргысын кычкыртты. Аңа җавап итеп, янәшәсендә кунаклап утырган тавыклар кыткылдарга тотынды, сыерлар мөгрәде. Акбай, оясыннан башын чыгарып, артык тавышланмагыз, Таңсылуны уятасыз, дигән кебек, өреп куйды.

Бу иртә Таңсылу өчен бик тә куанычлы. Бүген аның туган көне. Уянып ул озак иркәләнеп ятмады, солдатларча җәһәт кенә сикереп торды да, урын-җирен җыештырып, бүлмәсеннән чыкты. Әнкәсе пешергән тәмле коймак исе бөтен бүлмәгә таралган иде. Ул да түгел, бүлмә ишеген киң итеп ачып, зур чәчәк бәйләме тотып, әнисе килеп керде.

- Туган көнең белән сине, Таңсылуым, кояш нурым! - дип, Галия апа кызын кочагына алды.

- Рәхмәт, әнием.

- Самавырны яңартыйк, әтиең кергәч коймак белән чәй эчеп алырбыз.

Әхмәтҗан абзый озак көттермәде. Иртәнге эшләрен тәгәлләп, эре адымнар белән каты итеп басып, ишектән килеп тә керде.

- Бәрәкалла, кызым, иртәләгәнсең түгелме соң?

Галия апа иренә иелә төшеп, ярымпышылдаган тавыш белән генә:

- Әтисе, онытып җибәргәнсең, димме. Таңсылуның бүген туган көне - унсигез яше тулды, лабаса.

- И-и-и, хәтере тишек иләк кебек бит аның, онытып җибәргәнмен. Туган көнең белән, җимешем, - дип, әтисе Таңсылуны кысып кочып, битеннән үбеп алды.

- Бәхетле , сәламәт, тәүфыйклы, гомерле бул, балам.

Моннан 19 ел элек кенә аларның туйлары гөрләп узган иде. Ә менә хәзер алма кебек кызлары - Таңсылу белән Назгөл үсеп килә. И-и үтә дә соң гомерләр...

Җәйнең бик матур бер иртәсендә Галия ирен эшкә озатып, савыт-сабаларын җыештырып алды да, ял итәргә дип, диванга барып ятты. Башында йөз төрле уй бөтерелде: "Сау-сәламәт булып туса гына ярар иде сабыем, ике сабыйны да тиешенчә карый, акча җиткерә алырбызмы?.."

Галия йоклап киткәнен сизми дә калды. Ул төш күрде. Әхмәтҗан белән җитәкләшеп, күлә, шаяра болын буйлап киләләр. Каяндыр житен чәчен җилфердәтеп, яңгыравык тавыш белән көлә-көлә, нурлы йөзен балкытып, кечкенә генә кыз бала пәйда булды. Аның кашында ясмык кадәрле миңе дә бар. Ул аның йөзен тагын да сөй-кемләтеп тора иде. Кыз йөгереп килде дә Галиянең куенына сарылды, аны битеннән, күзләреннән үпте: "Әнием, әнием, мин сине шундый яратам," - дип пышылдады.

Бер атнадан соң Галия нәкъ төшендә күргән кызчыкка охшаган миңле кыз бала тапты. Галия белән Әхмәтҗанның куанычлары эчләренә сыймады. Таңсылу бик тиз тернәкләнде, яшь тулганда, тәпиләп тә китте. Сөйләп кебек тере, хәрәкәтчән, шук булды кыз. Шул шуклыгы аркасында, үлемнән чак калды. Таңсылуның чәчләрен үреп, матур күлмәкләрен кидергәннән соң, әтисе белән уйнарга дип, ишек алдына чыгарып җибәрде. Таңсылу тышта йөргән арада, Галия, кер юарга дип, тазга гөжләп торган су койды. Шул вакыт бүлмәгә бөтерчек кебек Таңсылу йөгереп тә керде, Галия "аһ" дияргә дә өлгермәде: кызы - күз нуры, тазга килеп тә төште.

Табиб Галияне юатырлык бернәрсә дә әйтмәде: "Нык, сабыр булыгыз, мондый тән җәрәхәте белән сабый көрәшә алмас, кулдан килгәннең барсын да эшләдек. "Галиянең аяк астында җир убылган кебек булды, тамагына төер тыгылды, кызы янында кайнашкан табибларны, янында гасабиланып йөргән ирен дә күрмәде. Аның күз алдында бары тик үлем белән якалашып яткан Таңсылу гына иде. Галия бертуктаусыз Ходайдан нарасыеның исәнлеген сорап ялварды.

Йокысыз, борчулы көн-төннәр артта калды. Ходайның рәхмәте белән, Таңсылу исән калды. Бу аның икенче тапкыр дөньяга килүе. Галия кызына карап туя алмый. Таңсылу эшкә уңган-булган, акыллы, чибәр кыз булып үсеп житте. Кыз, әнисе кебек, укытучы һөнәрен сайлады. Бары тик бу шомлы, хәтәр көннәрнең шаһиты булып, Таңсылуның тәнендәге җөйләре генә калды.

***Илүзә Кашапова, 8 нче а сыйныфы укучысы***

**ТЫЛСЫМ+**

**Март, 2015 нче ел**

***Мөслим гимназиясе укучылары газетасы***

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Исмәгыйлева Язилә
**Корректор:** Мөхәммәтханова Айгөл
**Корреспондентлар:** Әһлиуллина Язилә
Ханеева Камилә
**Дизайнер:** Хәбибуллин Руслан

**Компьютерда җыючылар:** Гилемов Азат
Ринат Сафиуллин
**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym